# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге составына керүче Максим Пүчинкәсе авылында 2026 елга үзара салым кертү турында

№ 8 29.10.2025 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчыстатьялары, «Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Максим Пүчинкәсе авылында узган гражданнар җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Максим Пүчинкәсе авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, 1,2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, күп балалы гаиләләрдән, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары кала, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттә гемәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту: (урамнары юлларын кардан чистарту һәм юлларны тигезләү);

-электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка билгеләнгән җайланмаларны ремонтлау: (агымдагы ремонт, урам утлары лампаларын сатып алу һәм алыштыру).

3.Әлеге карарны Кызыл Тау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнарҗыенындарәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе В.А. Гиззатуллина